**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының бердәм норматив хокукый актлар банкы турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасының бердәм норматив хокукый актлар банкын булдыру һәм алып бару тәртибен камилләштерү максатларында **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының бердәм норматив хокукый актлар банкы турында» 2002 елның 8 маендагы ПУ-352 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2002 елның 25 ноябрендәге ПУ-1031 номерлы, 2005 елның 7 сентябрендәге ПУ-361 номерлы, 2007 елның 9 гыйнварындагы ПУ-1 номерлы, 2008 елның 26 декабрендәге ПУ-687 номерлы һәм 2013 елның 10 августындагы ПУ-751 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, республика башкарма хакимият органнары кеше һәм граждан хокукларына, ирегенә һәм бурычларына кагылышлы, оешмаларның хокукый статусын билгели торган яисә ведомствоара әһәмияткә ия хокукый актлар чыккан көннән алып 3 эш көне эчендә аларның күчермәләрен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына электрон рәвештә бирергә тиеш.»;

б) 3 пунктта:

«, Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына», «, муниципаль хокукый актларны» сүзләрен төшереп калдырырга;

«алар тарафыннан кабул ителгән кеше һәм граждан хокукларына, ирегенә һәм бурычларына кагылышлы, оешмаларның хокукый статусын билгели торган хокукый актлар, муниципаль хокукый актлар кәгазьдә һәм электрон чыганакларда» сүзләрен «аның тарафыннан кеше һәм граждан хокукларына, ирегенә һәм бурычларына кагылышлы, оешмаларның хокукый статусын билгели торган хокукый актлар электрон рәвештә» сүзләренә алмаштырырга;

в) 4 пунктта «республиканың башка башкарма хакимият органнары» сүзләрен «ведомстволар (алга таба – республика башкарма хакимият органнары)» сүзләренә алмаштырырга;

г) 6 пунктның беренче абзацында «Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының хокукый мәгълүмат рәсми сайты»нда» сүзләрен «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда» сүзләренә алмаштырырга;

д) 8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актларын «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштыруны башкарырга тиеш.»;

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына үз актларын әлеге Указга туры китерергә.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан,Кремль
2015 ел, 06 март
№ ПУ-247